ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 сентября 2017 г. № 5872

Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карары белән расланган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карары (2016 елның 27 июнендәге 3269 номерлы, 2017 елның 30 гыйнварындагы 394 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 1.3.5 пункт өстәргә:

«1.3.5. Муниципаль хезмәт Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән күрсәтелә.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 1.3.6 пункт өстәргә:

«1.3.6. Мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән алынырга мөмкин.»;

3) 1.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.02.2017, № 8, ст.1249).».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин